**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**369** Казан шәһәре **06.09.2022**

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен үти торган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе бюджет кодексының $78^{1}$ маддәсенең 1 пункты икенче абзацы , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 ел, 22 феврале «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларда субсидияләр бирү күләмен һәм шартлары тәртибен билгеләүдә норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр» турындагы 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февралендәге «Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү шатларын һәм күләмен билгеләү тәртибен гамәлгә куючыларның Татарстан Республикасы дәүләт хөкүмәте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуы турында»гы 178 карары нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә куючыларның функцияләрен, вәкаләтләрен үти торган субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен расларга.
2. Боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

**Министр** **Т.Ж.Сөләйманов**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгы
боерыгы нигезендә расланды
06.09.2022 № 369

Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә куючыларның функцияләрен, вәкаләтләрен үти торган субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә куючыларның функцияләрен, вәкаләтләрен үти торган субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү кагыйдәләрен билгели( алга таба учреждение, гамәлгә куючы), чараларны тормышка ашыру өчен субсидияләр(алга таба – тәртип).

2. Әлеге Тәртиптә кулланылучы төп аңлатмалар:

подпрограмма – түбәндәге дәүләт программаларының подпрограммалары:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел 5 мартындагы 158 карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасында 2019-2025 елларга яшьләр сәясәте үсеше» дәүләт программасы;

«2019-2025 елларда балалар һәм яшьләр ялын оештыру» подпрограммасы;

«2019-2025 елларда Татарстан яшьләре» подпрограммасы;

«2019-2025 елларда Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия» подпрограммасы;

«2019-2025 елларда Татарстан балалары» подпрограммасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел 16 октябре, 764 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында 2014-2025 елларга иҗтимагый тәртип һәм хокук бозуларны булдырмауны тәэмин итү» дәүләт программасы;

«Татарстан Республикасында 2014-2025 елларга хокук бозулар һәм җинаятьчелекне кисәтү буенча эшчәнлекне оештыру» подпрограммасы; «Татарстан Республикасында 2019-2025 елларга балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү» подпрограммасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2014 ел 19 июль 512 номерлы «Татарстан Республикасында 2015-2025 елларга ришвәтчелеккә каршы сәясәтне тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау» карары белән расланган «Татарстан Республикасында 2015-2025 елларга ришвәтчелеккә каршы сәясәтне тормышка ашыру» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябре 821 нче номерлы «Татарстан Республикасында 2023-2030 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белщн расланган «Татарстан

Республикасында 2023-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел 25 августындагы 730нчы номерлы «Татар халкының милли бердәйлеген саклау» турындагы Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турындагы» карары белән расланган «Татар халкының милли бердәйлеген саклау (2020-2024 еллар)»Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел 31 октябрь 823 нче номерлы «Татарстан Республикасының 2014-2024 елларга икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» карары белән расланган ««Татарстан Республикасының 2014-2024 елларга икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы;

«Татарстан Республикасында 2014-2024 елларга социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм» подпрограммасы;

Гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, ул гамәлгә куючы функцияләрен вәкаләтләрен үти;

субсидия – субсидия, учреждениегә төп гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган тарафыннан билгеләнгән учреждениегә гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә торган

Субсидия-тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куючыга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә баш бүлүченең һәм акчаларны алучының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы учреждениегә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән чараны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә торган субсидия.

Әлеге Тәртиптә кулланылган терминнар һәм аңлатмалар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәдә кулланылалар.

3. Субсидия алу өчен учреждение гамәлгә куючы адресына субсидия алу өчен гариза бирә., аңа түбәндәге документлар кирә:

Учреждение бланкында субсидия алу өчен учреждениенең язма мөрәҗәгате;

Подпрограммада каралган чаралар үткәрү өчен якынча чыгымнар сметасын кертеп. әлеге Тәртипнең 1 пунктында билгеләнгән максатларга субсидия билгеләү кирәклеге нигезләнгән, учреждение җитәкчесе имзалаган аңлатма язу;

Субсидия алу максаты чаралар үткәрү булганда, чаралар программасы;

салым органының айның беренче санына булган белешмәсендә оешманың салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентларның булмавын раслаучы белешмә;

учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бурычлар, авария (гадәттән тыш) хәлне булдырмау,

нәтиҗәләрне бетерү һәм Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү очракларыннан тыш заявка бирелә торган айның беренче санында булмавы турында белешмә авария (гадәттән тыш) вәзгыять килеп туган очракта торгызу эшләре, законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка очраклар буенча бурычларны каплау, учреждениенең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан учреждениенең мөһере белән беркетелгән (булган очракта) имзаланган белешмә;

Тәкъдим ителгән документлар аңлаешлы итеп язылган булырга тиеш. Төзәтүләр һәм бетерүләр булмаска тиеш. Учреждение җитәкчесенең язмача мөрәҗәгате учреждение печаты(булган очракта) белән беркетелгән һәм гамәлгә куючының яки учреждение җитәкчесенең имзасы белән расланган булырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Ведомство карамагындагы учреждениеләр буенча дәүләт йөкләмәләрен һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәү турындаеллык хисапны формалаштыру өчен җаваплы министрлыкның структур бүлекчәләре исемлеген раслау турында» 2019 елның 15 гыйнвары 7 нче номерлы боерыгы нигезендә әлеге тәртипнең 3нче пункты буенча тапшырылган гаризаны теркәүдән соң 10 эш көне эчендә аны карый, мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеген тикшерә, учреждениегә субсидия бирү яки аны бирүне кире кагу турында хәбәр итә.

Учреждениегә субсидия бирүне кире кагуга нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тәкъдим ителгән документларның әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, яки тапшырылмавы( тулы күләмдә булмавы);

Учреждение тарафыннан тәкъдим ителгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәве.

5. Субсидия бирү турында карар кабул иткәннән соң, 10 эш көне эчендә гамәлгә куючы һәм учреждение Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының 2016 елның 22 декабре 17-148 нче номерлы «Россия Федерациясе бюджет кодексының 78.1.статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типовой формасын раслау хакында» приказында күрсәтелгән формада килешү төзиләр( алга таба –килешү), шул исәптән түбәндәге нигезләмәләр керә:

Подпрограмма атамасын күрсәтеп, субсидия билгеләү максатлары;

Подпрограммада билгеләнгән субсидия нәтиҗәләре әһәмияте;

Субсидия билгеләү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

Субсидия размеры;

Субсидия исәпләү срогы(графигы);

финанс ягыннан тәэмин ителеше субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планының гамәлгә ашырылуы турында

хисаплылык, иҗади хисап;

учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү тәртибе, шартлары һәм максатлары үтәлмәгән очракта, субсидия суммасын кире кайтару сроклары һәм тәртибе;

килешүгә, шул исәптән элек гамәлгә куючыга субсидия бирүгә билгеләнгән бюджет йөкләмәләренең лимитлары кимегән очракта үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе;

гамәлгә куючы карары (берьяклы тәртиптә) буенча килешүне срогыннан алда туктату өчен нигез булып тора:

учреждениенең юкка чыгуы яки аны үзгәртү;

учреждениенең әлеге тәртиптә һәм килешүдә күрсәтелгән субсидия шартларын һәм маусатларын бозуы;

учреждение тарафыннан берьяклы тәртиптә килешүне өзүне тыю;

финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирлә торган чыгымнарның юнәлешләре;

субсидияне исәплəү тәртибе һәм шартлары;

учреждениенең субсидияләр бирү шартлары үтәлеше тикшерүне гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга ризалыгы.

6. Субсидия күләме учреждениенең әлеге Тәртипнең 3нче пункты нигезендә бирелә торган гаризада чагылдырылган ихтыяҗын исәпкә алып, түбәндәге формула буенча гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә:

$$C = \sum_{i=1}^{5} З_i,$$

$З_1$ – Россия Федерациясе Хезмәт һәм салым законнары нигезендә учреждениенең локаль норматив актларында каралган штат расписаниесе нигезендә («2019-2025 елларга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру»ярдәмче программасына карата)вазыйфаи окладларны исәпкә алып билгеләнә торган ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган учреждение хезмәткәрләренең хезмәткә түләү фондын формалаштыруга тотылган чыгымнар;

$З_2$ – иминият взнослары турында хезмәт законнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган хезмәткәрләргә мәҗбүри социаль иминият түләүләре буенча взнослар түләүгә чыгымнар(«2019-2025 елларга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру» ярдәмче программасына карата);

$З_3$ – хезмәткә түләү фондыннан тыш, учреждение ихтыяҗыннан чыгып, Россия Федерациясе норматив актларын һәм гамәлгә куючы карарларын исәпкә алып, учреждение хезмәткәрләренә башка түләүләр өчен чыгымнар;

$З_4$ – подпрограмма нәтиҗәләре (ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) белән турыдан-туры бәйле булган оешманың ихтыяҗы буенча

товарлар җитештерү, эш башкару, хезмәт күрсәтү чыгымнары;

$З_5$ – учреждениенең Татарстан Республикасы норматив актлары һәм учреждениенең локаль норматив актлары белән җайга салынучы төп чараларның, матди булмаган активларның, матди запасларның бәясен арттыру чыгымнарын үз эченә алган финанс булмаган активларын арттыруга китерүче чыгымнар.

7. Гариза бирелгән айның беренче көненә учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычлар булмау;

Башкарма документлар буенча учреждениене үзгәртеп кору яки юк итү чараларын башкаруга субсидияләр бирү очракларыннан тыш, авария (гадәттән тыш) хәлне булдырмау, нәтиҗәләрне бетерү һәм авария (гадәттән тыш) вәзгыять килеп туган очракта торгызу эшләрен башкару очракларыннан тыш, башка хокукый актлар нигезендә закон нигезендә кергән суд актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Федераль законнары һәм норматив хокукый актлары белән билгеләнгән бүтән очраклар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча кичектерелгән бурычның булмавы.

8. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып килешүдә билгеләнгән ярдәмче программаның нәтиҗәләрен (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын) билгеләү тора.

9. Гамәлгә куючы килешүдә каралган субсидияне күчерү графигы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган учреждениенең исәп-хисап счетларына тулы күләмдә субсидия күчерә.

10. Учреждение гамәлгә куючыга бу Тәртипнең 5 нче пункты нигезендә хисапны киләсе срокларда тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә 1 нче номерлы кушымта нигезендә финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап, әлеге Тәртипкә 2 нче номерлы кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап;

хисап елының соңгы аеның 25 числосыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә карата 3 нче номерлы кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турындагы хисап;

Тапшырыла торган исә-хисап һәм беркетелгән документлар аңлаешлы итеп бастырылырга тиеш. Учреждение мөһере(булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле зат имзалаган яисә учреждение җитәкчесе тарафыннан үз куллары белән расланган төзәтмәләрдән тыш, чистарту һәм төзәтү кабул ителми.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап, әлеге Тәртипнең 1 нче номерлы кушымтасы нигезендә бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегендә архивка тапшырылганчы кабул ителә һәм саклана.

Әлеге Тәртипкә 2 нче номерлы кушымта нигезендә форма буенча нәтиҗәләргә ирешү турында хисап, 3 нче номерлы кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2019 нчы елның 15 нче гыйнварындагы «Ведомство карамагындагы учреждениеләр буенча Дәүләт йөкләмәләрен һәм Дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында еллык хисапны формалаштыру өчен җаваплы министрлыкның структур бүлекчәләре исемлеген раслау турында»гы 7 нче номерлы боерыгы нигезендә структур бүлекчәдә архивка тапшырылганчы кабул ителә һәм саклана.

Оешма нигез салучыга килешү нигезендә өстәмә отчетлар бирә.

11. Дәүләт финанс контролен гамәлгә куючы һәм вәкаләтле орган учреждениегә субсидияләр бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен контрольдә тота.

12. Структур бүлекчә җитәкчесе йөзендә оештыручы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2019 нчы елның 15 нче гыйнварындагы «Ведомство карамагындагы учреждениеләр буенча Дәүләт йөкләмәләрен һәм Дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында еллык хисапны формалаштыру өчен җаваплы министрлыкның структур бүлекчәләре исемлеген раслау турында»гы 7 нче номерлы боерыгы нигезендә килешү кысаларында учреждение тарафыннан алынган субсидияләрне максатчан тотуны арадаш һәм йомгаклау тикшерүне түбәндәге юл белән гамәлгә ашыра:

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап нигезендә планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр уздыру;

субсидия куллану белән бәйле учреждение тарафыннан башкарылган операцияләрне документаль һәм фактик яктан анализлау;

әлеге Тәртипкә карата 1 нче номерлы кушымтада билгеләнгән субсидияләр бирү һәм учреждение хисаплары нигезендә ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен учреждениеләр тарафыннан ирешүнең арадаш һәм йомгаклау бәяләмәсе.

13. Учреждение әлеге Тәртип нигезендә субсидия алу өчен яисә субсидиядән файдалану, субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозу турында, шулай ук субсидия тоту максатлары, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырмау, һәм (яисә) нәтиҗәләргә ирешү турында хисап, субсидия, иҗади хисап бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын тормышка ашыру турында хисап, субсидияләрне максатчан билгеләнеше буенча файдаланмау, субпрограммада һәм килешүдә билгеләнгән нәтиҗәләр күрсәткечләрен (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) ирешмәүгә бәйле дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру өчен җаваплы.

Документ белән рәсмиләштерелгән, барлыкка килгән җиңеп булмаслык көчнең тиешле йөкләмәләрне гамәлгә ашырырга комачаулый торган шартлар учреждениене җаваплылык чараларын кулланудан азат итүнең нигезе булып тора.

14. Гамәлгә куючы, шулай ук вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүе органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларын һәм максатларын бозу фактлары билгеләнгән очракта, тиешле субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге тәртиптә кире кайтарылырга тиеш:

гамәлгә куючы таләбе нигезендә-әлеге акчаларны бозу очрагы теркәлгән субсидия күләмендә кире кайтару турында таләп алынганнан соң 30 эш көне эчендә;

тиешле дәүләт финанс контроле органы күрсәтмәсе һәм (яисә) боерыгы нигезендә-Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән срокларда.

Килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәләре җитмәгән очракта, субсидия, гамәлгә куючының тиешле таләбен алган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

15. Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылган очракта, гамәлгә куючы күрсәтелгән срок чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына мәҗбүри рәвештә түләтеп алу буенча чаралар күрә.

16. Агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә субсидияләрнең кулланылмаган өлеше Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 1 пункты нигезендә, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр өлеше финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләрнең булуы турында учреждениенең мөрәҗәгате, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләрнең барлыгын һәм күләмен раслаучы документлар (документлар күчермәләре) (физик затларга түләү буенча йөкләмәләрдән тыш) нигезендә субсидияләр бирү елыннан соң килгән елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән (алга таба-субсидия калдыклары буенча учреждение мөрәҗәгате) агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчалары максатларга ирешү өчен кирәк булуы турындагы Карар кабул итә.

Гамәлгә куючы кулланылмаган субсидия өлеше буенча учреждение мөрәҗәгатен алганнан соң биш эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 1 нче пункты нигезендә агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчаларын максатларга ирешүгә юнәлдерүгә ихтыяҗ булу турында Карар кабул итә.

17. Әлеге Тәртипнең 1 нче пункты нигезендә максатларга ирешүгә юнәлдерелгән агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидияләр акчаларына ихтыяҗ булу турындагы гамәлгә куючы карары нигезендә, әлеге субсидиянең кулланлмаган өлеше агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 нче пункты нигезендә максатка юнәлдерелгән чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү өчен кулланылырга мөмкин.

18. Әлеге Тәртипнең 1 нче пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен, агымдагы финанс елында учреждение финанс тәэмин итү чыганагы итеп субсидияләр торган элек чыгарган түләүләрне кире кайтарудан кергән

акчалар булса, гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы элек учреждение тарафыннан түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акча торган үтәлмәгән йөкләмәләр булу турында учреждение мөрәҗәгате, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләрнең барлыгын һәм күләмен раслаучы документлар (документлар күчермәләре) (физик затларга түләү буенча йөкләмәләрдән тыш) нигезендә, субсидияләр бирү елыннан соң килгән елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән (алга таба-субсидия калдыклары буенча учреждение мөрәҗәгате) агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчалары максатларга ирешү өчен кирәк булуы турындагы Карар кабул итә.

Гамәлгә куючы, әлеге Тәртипнең 1 нче пункты белән билгеләнгән максатларга ирешү өчен, учреждение элек түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акчалар буенча мөрәҗәгать иткәннән соң биш эш көне дәвамында агымдагы финанс елында учреждение тарафыннан элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчаларны субсидия торган түләүләрне файдалану турындагы Карар кабул итә.

19. Субсидияне гамәлгә куючы тарафыннан бирелү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кушымта № 1

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен үти торган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә

Форма

«__» ______20__ көненә
финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап

Учреждение исеме: ________________________________________
Ешлык: квартал саен
Үлчәү берәмлеге: сум (төгәллеге белән икенче унлык билгесенә кадәр)

| | Сумма | |
|---|---|---|
| | хисап чоры вакытына | ел башыннан алып арта барган нәтиҗә белән |
| *1* | *2* | *3* |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән субсидияләр | | |
| Субсидиядән (касса чыгымнары) тотылган акчалар | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылган | | |
| Хисап чоры ахырына субсидия саны | | |
| шул исәптән: кире кайтарылуга дучар булган | | |

Структур бүлекчә җитәкчесе

_______/ ___________________________
Фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта)

Учреждение

_______/ ___________________________
Фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта)

М.П.

«___»________________202_ел

«___»________________202__ел

Кушымта № 2

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен үти торган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә

Форма

«__» ______20__ көненә нәтиҗәләргә ирешү турындагы хисап

Учреждение исеме __________________________________________
Ешлык: квартал саен

| № п/п | Нәтиҗә исеме | 20__елга план күрсәткече | Хисап датасына ирешелгән нәтиҗәләр | Башкарылган план проценты | Тайпылыш сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* |
| | | | | | |

Структур бүлекчә җитәкчесе

_______/ ___________________________
Фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта)

«___»________________202_ел

Учреждение

_______/ ___________________________
Фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта)

М.П.

«___»________________202__ел

Кушымта № 3

Татарстан Республикасы бюджетыннан
Татарстан Республикасы дәүләт бюджет
һәм автоном учреждениеләренә Татарстан
Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы
гамәлгә куючының функцияләрен һәм
вәкаләтләрен үти торган башка максатларга
субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын
билгеләү тәртибенә

Форма

_________ 20__ ел. көненә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турындагы хисап

________

| | | | КОД |
|---|---|---|---|
| | | Дата | |
| | | Җыелма реестр буенча | |
| Учреждение исеме | | ИНН | |
| Бюджет акчаларын баш бүлүченең исеме | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | Җыелма реестр буенча | |
| Дәүләт программасы чарасының исеме | | БК буенча | |
| Субсидия исеме | | БК буенча | |

Килеш
Килешу

Документ төре

(беренчел - "0", ачыкланган - "1", "2", "3", "...")

| Субсидия бирү нәтиҗәсе | | | Үлчәү берәмлеге | | Күрсәткеч | | |Ирешү (кк.аа.е |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | код | тип | исеме | ОКЕИ буенча коды | пландагы | фактик | көтелгән | пландагы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль пунктлары | х | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль пунктлары | х | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| субсидия бирү нәтиҗәсе | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль пунктлары | x | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль пунктлары | x | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Структур бүлекчә җитәкчесе

_______/ ___________________________
Фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта)

«___»_________________202_ел

Учреждение

_______/ ____________
Фамилия, исем, атасы и

М.П.

«___»__________